Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авыл башкарма комитеты

КАРАРЫ

26 июнь 2023 ел № 5

Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31 августындагы 14 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» 2021 елның 12 маендагы 55 нче номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары, 2022 елның 1 мартыннан кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешү нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 10 апреленнән 02-08-01/176 номерлы протестын карап

Иске Михайловка авыл башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31 августындагы 14 номерлы карары үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Иске Михайловка авылы, Школьная урамы, 43 йорт; Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йорты территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Михайловка авыл башкарма
комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.А. Миназева